# РӘСӘЙ ФЕДЕРАЦИЯСЕ

# ТУПЛАНМА ПЕНСИЯГӘ ӨСТӘМӘ ИМИНИЯТ КЕРТЕМНӘРЕ ҺӘМ ПЕНСИЯ ТУПЛАНМАЛАРЫН ФОРМАЛАШТЫРУГА ДӘҮЛӘТ ЯРДӘМЕ ТУРЫНДА

# ФЕДЕРАЛЬ КАНУН

2008 елның 18 апрелендә

Дәүләт Думасы тарафыннан

кабул ителгән

2008 елның 25 апрелендә

Федерация Советы тарафыннан

хупланган

## Маддә 1. Әлеге Федераль канунны җайга салу предметы

Әлеге Федераль канун пенсия тупланмаларын формалаштыруны стимуллаштыру һәм гражданнарны пенсия белән тәэмин итү дәрәҗәсен арттыру максатларында 2001 елның 15 декабреннән 167-ФЗ номерлы "Рәсәй Федерациясендә мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе турында" Федераль канун (алга таба – "Рәсәй Федерациясендә мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе турында" Федераль канун) нигезендә тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү максатларында мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе буенча хокукый мөнәсәбәтләргә ирекле керү тәртибен билгели, тупланма пенсиягә, тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен, эш бирүче кертемнәрен түләү, шулай ук пенсия тупланмаларын формалаштыруга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибен һәм шартларын билгели.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 2. Әлеге Федераль канунда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Федераль канун максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) иминиятләштерелгән зат – тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү максатларында "Рәсәй Федерациясендә мәҗбүри пенсия иминияте турында" Федераль канун нигезендә мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе буенча хокукый мөнәсәбәтләренә ирекле рәвештә кергән зат;

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

2) тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләүче иминиятләштерелгән затның эш бирүчесе (алга таба-эш бирүче) – "Рәсәй Федерациясендә мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе турында" Федераль канун нигезендә күрсәтелгән иминиятләштерелгән зат өчен мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе буенча иминиятләштерүче булып торучы зат;

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

3) тупланма пенсияuо өстәмә иминият кертеме – әлеге Федераль канун тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда эш бирүче тарафыннан исәпләнә, тотып калына һәм күчерелә торган яисә иминиятләштерелгән зат тарафыннан мөстәкыйль рәвештә иминиятләштерелгән затның үз акчалары хисабына түләнә торган индивидуаль кайтарыла торган түләү;

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

4) пенсия тупланмаларын формалаштыруга дәүләт ярдәме – федераль бюджет составында барлыкка килгән Милли муллык фонды акчалары хисабына гамәлгә ашырыла торган һәм әлеге Федераль канун тарафыннан билгеләнгән шартларда һәм тәртиптә тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түлгән затның файдасына Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды бюджетына күчерелә торган пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашуга кертемнәр;

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

5) эш бирүченең кертеме – әлеге Федераль канун тарафыннан билгеләнгән шартларда һәм тәртиптә иминиятләштерелгән зат файдасына түләнә торган эш бирүче акчалары.

**Маддә 3. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү максатларында мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе буенча хокукый мөнәсәбәтләр**

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

1. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү максатларында мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе буенча хокукый мөнәсәбәтләр затның әлеге Федераль канунда билгеләнгән тәртиптә тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү максатларында мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе буенча хокукый мөнәсәбәтләргә ирекле керү турында гариза нигезендә барлыкка килә.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

2. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү максатларында мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе буенча хокукый мөнәсәбәтләргә кергән һәм аларны түләү белән шөгыльләнүче иминиятләштерелгән зат күрсәтелгән кертемнәрнең түләвен туктатырга яисә яңартырга, шулай ук аларның күләмен билгеләргә хокуклы.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

3. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәре исәбеннән, эш бирүченең кертемнәреннән, пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашуга кертемнәрдән формалаштырылган тупланма пенсиягә алу хокукы 2013 елның 28 декабреннән 424-ФЗ номерлы "Тупланма пенсия турында" Федераль канун (алга таба – "Тупланма пенсия турында" Федераль канун) тарафыннан билгеләнгән шартларны үтәгәндә гамәлгә ашырыла.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 4. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү максатларында мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе буенча хокукый мөнәсәбәтләргә ирекле керү турында гариза**

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

1. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү максатларында мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе буенча хокукый мөнәсәбәтләргә ирекле керү турында гариза (шулай ук алга таба – гариза) Рәсәй Федерациясе Пенсия фондының территориаль органына шәхсән гражданин, аның эш бирүчесе аша яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәге аша бирелә ала. Гариза шулай ук башка ысул белән, шул исәптән, Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган һәм аларга керү билгеле бер затлар даирәсе белән чикләнмәгән мәгълүмати-телекомуникацион челтәрләрен кулланып, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын кулланып бирелә торган электрон документ формасында дә бирелергә мөмкин, шул ук вакытта, шәхесне билгеләү һәм гражданин имзасының чынлыгын тикшерү 2002 елның 24 июленнән 111 - ФЗ номерлы "Рәсәй Федерациясендә тупланма пенсияне финанслау өчен чараларны инвестицияләү турында" Федераль канунның (алга таба – "Рәсәй Федерациясендә тупланма пенсияне финанслау өчен чараларны инвестицияләү турында" Федераль канун) 32 маддәсенең 4 пунктының 1-4 пунктачалары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

(27.07.2010 нән 227-ФЗ номерлы, 11.07.2011 нән 200-ФЗ номерлы, 28.07.2012 нән 133-ФЗ номерлы, 21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы, 04.06.2018 нән 138-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

2. Гаризада күрсәтелергә тиеш мәгълүматлар:

1) гражданинның шәхси счетының иминият номеры;

2) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

3) гражданинның яшәү урыны.

3. Гариза формасы һәм аны тутыру буенча күрсәтмә Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан раслана.

4. Гариза алган эш бирүче гариза алган көннән өч эш көненнән артмаган вакытта аны мәҗбүри пенсия иминиятләштерүгә буенча иминиятләштерүче сыйфатында теркәлү урыны буенча турыдан-туры Рәсәй Федерациясе Пенсия фондының территориаль органына яисә күпфункцияле үзәк аша җибәрә. Хезмәтчеләренең уртача саны алдагы календарь ел эчендә 25 кешедән артып киткән эш бирүчеләр, шулай ук югарыда күрсәтелгән саннан артып киткән хезмәткәрләр тоткан әле генә (шул исәптән үзгәртеп кору юлы белән) төзелгән оешмалар, алынган гаризаларны Рәсәй Федерациясе Пенсия фондының территориаль органына тикшерүнең төре һәм тәртибе Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан билгеләнгән электрон имза белән имзаланган электрон документлар формасында тапшыра. Шундый ук тәртиптә алынган гаризалар Рәсәй Федерациясе Пенсия фондының территориаль органына хезмәтчеләренең уртача саны алдагы календарь ел эчендә 25 кеше тәшкил иткән яки 25 кешедән кимрәк булган эш бирүчеләр тарафыннан тапшырылырга мөмкин. Күрсәтелгән гаризаны электрон документ формасында тапшыру форматы Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан билгеләнә.

(27.07.2010 нән 227-ФЗ номерлы, 28.07.2012 нән 133-ФЗ номерлы, 12.03.2014 нән 33-ФЗ номерлы, 21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы, 04.11.2014 нән 345-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

5. Гариза алган Рәсәй Федерациясе Пенсия фондының территориаль органы гариза алган көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча гражданинга гариза алу, аны карау нәтиҗәләре һәм тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү максатларында мәҗбүри пенсия иминияте буенча хокукый мөнәсәбәтләргә керү датасы турында хәбәрнамә җибәрә. Граждинин гаризаны электрон документ формасында биргән очракта әлеге хәбәрнамә гражданинга аларга керү билгеле бер затлар даирәсе белән чикләнмәгән мәгълүмати-телекомуникацион челтәрләрен

кулланып, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын кулланып тапшырыла.

(27.07.2010 нән 227-ФЗ номерлы, 11.07.2011 нән 200-ФЗ номерлы, 21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

6. 1996 елның 1 апреленнән 27-ФЗ номерлы "Мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында" Федераль канун (алга таба – "Мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында" Федераль канун) нигезендә шәхси счеты ачылмаган гражданин гариза бирү белән беррәттән әлеге Федераль канунда күрсәтелгән нигезендә шәхсән үзе яисә башка ысул белән, шул исәптән аларга керү билгеле бер затлар даирәсе белән чикләнмәгән мәгълүмати-телекомуникацион челтәрләрен кулланып, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын кулланып башлангыч теркәлүдә кирәкле белешмәләр бирә һәм әлеге Федераль канун нигезендә иминиятләштерелгән зат буларак теркәлә.

(27.07.2010 нән 227-ФЗ номерлы, 11.07.2011 нән 200-ФЗ номерлы, 21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

7. Гаризада кирәкле мәгълүматлар булмаган һәм (яки) кирәкле мәгълүматлар тапшырылмаган очракта Рәсәй Федерациясе Пенсия фондының территориаль органы гариза биргән гражданинга тиешле аңлатмалар бирә. Гариза электрон документ формасында тапшырылган очракта Рәсәй Федерациясе Пенсия фондының территориаль органы аңлатмаларны электрон документ формасында аларга керү билгеле бер затлар даирәсе белән чикләнмәгән мәгълүмати-телекомуникацион челтәрләрен кулланып, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын кулланып бирә.

(27.07.2010 нән 227-ФЗ номерлы, 11.07.2011 нән 200-ФЗ номерлы, 21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

8. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен, эш бирүченең кертемнәрен, пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашуга өстәмә иминият кертемнәрен түләү белән бәйле иминиятләштерелгән затларның шәхси мәгълүматлары дәүләти мәгълүмат ресурсы булып тора, аның фунцияләрен Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды башкара.

(27.07.2014 нән 227-ФЗ номерлы, 11.07.2011 нән 200-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

**Маддә 5. Тупланма пенсия өчен өстәмә иминият кертеме**

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

1. Тупланма пенсиягә түләнә торган өстәмә иминият кертеменең күләме иминиятләштерелгән зат тарафыннан мөстәкыйль рәвештә билгеләнә.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

2. Тупланма пенсия өчен өстәмә иминият кертемнәрен эш бирүче аша күчерү юлы белән түләргә теләүче иминиятләштерелгән зат әлеге кертемнәрне түләү турында гаризада мәҗбүри пенсия иминиятләштерүенә иминият кертемнәрен исәпләү өчен каты билгеләнгән күләмдә яисә база процентларында билгеләнгән тупланма пенсиягә ай саен түләнә торган өстәмә иминият керетеменең күләмен күрсәтә. Иминиятләштерелгән зат тарафыннан түләнгән тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертеменең күләме иминләштерелгән зат тарафыннан гариза нигезендә үзгәртелергә мөмкин.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

3. Иминиятләштерелгән зат белән хезмәт хокукый мөнәсәбәтләре һәм (яки) хокукый тиешле гражданнар-хокукый килешүләр буенча хокукый мөнәсәбәтләр туктатылган очракта эш бирүче күрсәтелгән хокукый мөнәсәбәтләр туктатаылган көннән алып иминиятләштерелгән затның тиешле гаризасыннан башка тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен исәпләүне, тотып калуны һәм күчерүне туктата.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

4. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәре тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләгән иминләштерелгән затның пенсия тупланмалары составына кертелә.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 6. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемен мөстәкыйль түләү тәртибе**

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

1. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемен түләү Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды бюджетына кредит оешмасы аша акча күчерү юлы белән күрсәтелгән кертемне мөстәкыйль түләүче иминиятләштерелгән зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

2. Мондый түләү гамәлгә ашырылган квартал тәмамланганнан соң 20 эш көненнән дә соңга калмыйча иминиятләштерелгән зат өстәмә иминият кертемнәрен мөстәкыйль рәвештә түләгән очракта ул Рәсәй Федерациясе Пенсия фондының территориаль органына тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләүне раслаучы документ күчермәсен тәкъдим итәргә яки мондый документны аларга керү билгеле бер затлар даирәсе белән чикләнмәгән мәгълүмати-телекомуникацион челтәрләрен кулланып, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын кулланып электрон документ (электрон документның электрон күчермәсе) формасында җибәрергә хокуклы.

(2 өлеш 04.06.2018 нән 138-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 7. Эш бирүче тарафыннан тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен исәпләү һәм тотып калу тәртибе**

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

1. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәре эш бирүче тарафыннан ай саен һәр иминиятләштерелгән затка карата аерым исәпләнә.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

2. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү яки тупланма пенсиягә түләнә торган өстәмә иминият кертеменең күләмен үзгәртү турында гариза алган эш бирүче тиешле гариза алу аеннан соң килә торган айның беренче числосыннан тупланма пенсиясенә өстәмә иминият кертемнәрен исәпләүне, тотып калуны һәм күчерүне гамәлгә ашыра. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемлнәрен түләүне туктату яисә яңарту шулай тиешле гариза тәкъдим итү аеннан соң килә торган айның беренче числосыннан гамәлгә ашырыла.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 8. Эш бирүче кертемнәре**

1. Эш бирүче тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләүче иминиятләштерелгән затлар файдасына эш бирүченең кертемнәрен түләү турында карар кабул итәргә хокуклы. Күрсәтелгән карар аерым боерык рәвешендә яки тиешле нигезләмәләрне коллектив яисә хезмәт шкилешүенә кертү юлы белән рәсмиләштерелә.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

2. Иминиятләштерелгән зат белән хезмәт хокукый мөнәсәбәтләре һәм (яки) хокукый тиешле гражданнар-хокукый килешүләр буенча хокукый мөнәсәбәтләр туктатылган очракта әлеге иминиятләштерелгән зат файдасына эш бирүченең кертемнәрен түләү күрсәтелгән хокукый мөнәсәбәтләр туктатылган көннән алып туктатыла.

3. Эш бирүченең кертемнәре күләме ай саен файдасына әлеге кертемнәр түләнгән һәр иминиятләштерелгән затка карата исәпләнә (билгеләнә).

4. Эш бирүченең кертемнәре файдасына әлеге кертемнәр түләнгән иминиятләштерелгән затларның пенсия тупланмалары составына керә.

**Маддә 9. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен һәм эш бирүченең кертемнәрен күчерү тәртибе**

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

1. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәре һәм эш бирүченең кертемнәре Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды бюджетына мәҗбүри пенсия иминиятләштерүенә иминият кертемнәрен түләүгә карата "Рәсәй Федерациясендә мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе турында" Федераль канун тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда күчерелә.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

2. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәре һәм эш бирүченең кертемнәре Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды бюджеты акчалары белән операцияләрне исәпкә алу өчен Рәсәй Федерациясе Үзәк банкы бүлекчәсендә Федераль казначылыкның территориаль органына ачылган аерым счетка күчерелә.

(2 өлеш 21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

3. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен һәм эш бирүченең кертемнәрен күчерү эш бирүче тарафыннан аерым түләүләр белән башкарыла һәм аерым түләү йөкләмәләре белән рәсмиләштерелә.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы, 04.11.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

4. Эш бирүче тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнщрен күчерү белән бергә иминиятләштерелгән затларның реестрын формалаштыра. Күрсәтелгән реестрлар тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәре суммасына һәм эш бирүче кертемнәренә карата аерым формалаша. Реестрда түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) тупланма пенсиягә күчерелгән барлык өстәмә иминият кертемнәренең суммасын үз эченә алган күчерелгән акчаларның гомуми суммасы (эш бирүченең барлык түләнә торган кертемнәрнең суммасы);

2) түләү йөкләмәсе номеры һәм аны үтәү датасы;

3) иминиятләштерелгән һәр затның шәхси счетының иминият номеры;

4) һәр иминиятләштерелгән затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме;

5) һәр иминиятләштерелгән затның тупланма пенсиягә күчерелгән өстәмә иминият кертемнәре суммасы (һәр иминиятләштерелгән зат файдасына түләнә торган эш бирүченең кертемнәре суммасы);

6) түләү чоры.

(4 өлеш 04.11.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

5. Әлеге маддәнең 4 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән белешмәләр тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен күчерү гамәлгә ашырылган кредит оешмасы тарафыннан расланырга тиеш.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

6. Иминиятләштерелгән затлар реестрлары эш бирүче тарафыннан Рәсәй Федерациясе Пенсия фондының территориаль органына дәвамында эш бирүченең кертемнәре түләнгән (аларны түләү очрагында) һәм тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәре күчерелгән квартал тәмамланганнан соң 20 көннән дә соңга калмыйча турыдан-туры яисә күпфункцияле үзәк аша тапшырыла. Иминиятләштерелгән затлар реестры формасы һәм аны тапшыру тәртибе Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан раслана.

(28.07.2012 нән 133-ФЗ номерлы, 21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

7. Хезмәтчеләренең уртача саны алдагы календарь ел эчендә 25 кешедән артып киткән эш бирүчеләр, шулай ук югарыда күрсәтелгән саннан артып киткән хезмәткәрләр тоткан әле генә (шул исәптән үзгәртеп кору юлы белән) төзелгән оешмалар Рәсәй Федерациясе Пенсия фондының территориаль органына яки күпфункцияле үзәк аша 2011 елның 6 апреленнән 63-ФЗ номерлы "Электрон имза турында" Федераль канун нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган иминиятләштерелгән затлар реестрлары тәкъдим итә. Шундый ук тәртиптә иминиятләштерелгән затлар реестрлары Рәсәй Федерациясе Пенсия фондының территориаль органына яки күпфункцияле үзәк аша хезмәтчеләренең уртача саны алдагы календарь ел эчендә 25 кеше тәшкил иткән яки 25 кешедән кимрәк булган эш бирүчеләр тарафыннан тапшырылырга мөмкин. Реестрны электрон формада тапшыру форматы Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан раслана.

(28.07.2012 нән 133-ФЗ номерлы, 21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы, 04.11.2014 нән 345-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

8. Эш бирүче Рәсәй Федерациясенең хезмәт канунчылыгы нигезендә исәп-хисап кәгазе белән беррәттән иминиятләштерелгән затларга тупланма пенсиягә исәпләнгән, тотып калынган һәм күчерелгән өстәмә иминият кертемнәре турында һәм иминиятләштерелгән затлар файдасына түләнгән эш бирүченең кертемнәре турында мәгълүмат бирә.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 10. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен һәм эш бирүченең кертемнәрен инвестицияләү**

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

1. Рәсәй Федерациясе Пенсия фондына килгән тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәре һәм эш бирүченең кертемнәре суммасы иминиятләштерелгән затның шәхси счетының махсус өлешендә чагылдырылганчы "Рәсәй Федерациясендә тупланма пенсияне финанслау өчен акча инвестицияләү турында"

Федераль канун нигезендә тупланма пенсияне финанслауга иминият кертемнәрен инвестицияләү өчен билгеләнгән тәртиптә инвестицияләнә.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

2. Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәре, эш бирүче кертемнәре, шулай ук аларны инвестицияләүдән кергән керем Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан иминиятләштерелгән затның шәхси счетының махсус өлешендә чагылдырыла һәм "Рәсәй Федерациясендә тупланма пенсияне финанслау өчен акча инвестицияләү турында" Федераль канун һәм 1998 елның 7 маеннан 75-ФЗ номерлы "Дәүләтнеке булмаган пенсия фондлары турында" Федераль канун тарафыннан билгеләнгән нигезләр һәм тәртиптә идарәче компанияләргә һәм дәүләтнеке булмаган пенсия фондларына тапшырыла.

Күрсәтелгән акчалар иминиятләштерелгән затның шәхси счетының махсус өлешендә чагылдырылырга һәм идарәче компанияләргә һәм дәүләтнеке булмаган пенсия фондларына тапшырылырга тиеш булган срок Рәсәй Федерациясе Пенсия фондының территориаль органы узган квартал өчен иминиятләштерелгән затлар реестрларын яки тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү иминиятләштерелгән зат тарафыннан мөстәкыйль рәвештә түләнгән очракта узган квартал өчен тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү турында белешмәләрне алган көннән өч айдан артмаска тиеш.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы, 04.11.2014 нән 345-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

### Маддә 11. Инвестиция портфелен (идарәче компанияне) сайлау, пенсия тупланмалары акчаларын дәүләтнеке булмаган пенсия фондына күчерү

1. Иминиятләштерелгән затлар инвестиция портфелен (идарәче компанияне) сайларга яки пенсия тупланмалары акчаларын дәүләтнеке булмаган пенсия фондына "Рәсәй Федерациясендә тупланма пенсияне финанслау өчен акчаларны инвестицияләү турында" Федераль канун һәм "Дәүләтнеке булмаган пенсия

фондлары турында" Федераль канун нигезендә билгеләнгән тәртиптә күчерергә хокуклы.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

2. Элек тупланма пенсиягә иминият кертемнәре түләнмәгән һәм "Рәсәй Федерациясендә мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе турында" Федераль канун нигезендә тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү максатларында мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе буенча хокукый мөгәсәбәтләргә беренче тапкыр кергән затлар, шулай ук элек инвестиция портфелен (идарәче компанияне) сайлап алуга яки пенсия тупланмалары акчаларын дәүләтнеке булмаган пенсия фондына күчерүгә хокукларын гамәлгә ашырмаган затлар тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү максатларында мәҗбүри пенсия иминияте буенча хокукый мөнәсәбәтләргә ирекле керү турында гариза биргәндә инвестиция портфелен (идарәче компанияне) сайлап алу турында гариза яисә дәүләтнеке булмаган пенсия фонды белән мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе турында килешү төзү шарты белән пенсия тупланмалары акчаларын дәүләтнеке булмаган пенсия фондына күчерү турында гариза бирергә хокуклы. Гариза электрон документ формасында Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә һәм аларга керү билгеле бер затлар даирәсе белән чикләнмәгән мәгълүмати-телекомуникацион челтәрләрен кулланып, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын кулланып тапшырылырга мөмкин.

(27.07.2010 нән 227-ФЗ номерлы, 11.07.2011 нән 200-ФЗ номерлы, 21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль кануннар редакциясендә)

3. Әлеге матдәнең 2 өлешендә күрсәтелгән затларның инвестиция портфелен (идарәче компанине) сайлап алу яки пенсия тупланмалары акчаларын дәүләтнеке булмаган пенсия фондына күчерү турында гаризаларны Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды "Рәсәй Федерациясендә тупланма пенсияне финанслау өчен акча инвестицияләү турында" Федераль канун һәм "Дәүләтнеке булмаган пенсия фондлары турында" Федераль канун нигезендә билгеләнгән тәртиптә карый һәм

тиешле гариза алган көннән алып өч айдан да артмаган вакытта тиешле акчаларның күчерүен гамәлгә ашыра.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

4. Иминиятләштерелгән зат тарафыннан түләнә торган тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәре суммасы, шулай ук элек инвестиция портфелен (идарәче компанияне) сайлап алуга яки "Рәсәй Федерациясендә тупланма пенсияне финанслау өчен акча инвестицияләү турында" Федераль канун һәм "Дәүләтнеке булмаган пенсия фондлары турында" Федераль канун нигезендә пенсия тупланмаларын дәүләтнеке булмаган пенсия фондына күчерүгә хокукын гамәлгә ашырган зат файдасына түләнә торган эш бирүченең кертемнәре суммасы аларны иминиятләштерелгән затның шәхси счетының махсус өлешендә исәпкә алганнан соң иминиятләштерелгән зат сайлавы нигезендә идарәче компаниягә яки дәүләтнеке булмаган пенсия фондына тапшырыла. Мондый иминиятләштерелгән зат күрсәтелгән федераль кануннарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда башка инвестиция портфелен (башка идарәче компанияне) сайлап алу турында гариза яки дәүләтнеке булмаган пенсия фондына (башка дәүләтнеке булмаган пенсия фондына) пенсия тупланмалары акчаларын күчерү турында гариза бирергә хокуклы.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

5. Файдаларын хезмәт пенсиясенең тупланма өлешенә иминият кертемнәре 2002 елдан 2004 елга кадәр түләнгән 1953-1966 елларда туган ир-атлар һәм 1957-1966 елларда туган хатын-кызлар әлеге маддәдә каралган тәртиптә инвестиция портфелен (идарәче компанияне) сайлап алырга яисә пенсия тупланмаларын дәүләтнеке булмаган пенсия фондына күчерергә хокуклы.

**Маддә 12. Пенсия тупланмаларын формалаштыруга дәүләт ярдәме**

1. Пенсия тупланмаларын формалаштыруга дәүләт ярдәме алу хокукына әлеге Федераль канунда билгеләнгән тәртиптә 2008 елның 1 октябренә кадәр тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәре түләү максатларында мәҗбүри пенсия иминиятләштерү буенча ирекле рәвештә хокукый мөнәсәбәтләргә керү турында

гариза биргән һәм 2015 елның 31 гыйнварга кадәр күрсәтелгән кертемнәрне түли башлаган иминиятләштерелгән затлар ия. Шул ук вакытта "Хезмәт пенсиясенең тупланма өлешенә өстәмә иминият кертемнәре һәм пенсия тупланмаларын формалаштыруга дәүләт ярдәме турында "Федераль канунга һәм Рәсәй Федерациясенең аерым канун чыгаручы актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль канун үз көченә кергән көннән соң тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү максатларында мәҗбүри пенсия иминияте буенча хокук мөнәсәбәтләренә кергән иминләштерелгән затлар әлеге Федераль канунда каралган тәртиптә пенсия тупланмаларын формалаштыруга дәүләт ярдәме алу хокукына ия, әгәр дә алар тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү максатларында мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе буенча хокукый мөнәсәбәтләргә ирекле керү турында гариза биргән көнгә 1993 елның 12 февраленнән 4468-ФЗ номерлы "Эчке эшләр органнарында, Дәүләт янгынга каршы хезмәтендә, наркотик дарулар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольда тоту оешмаларында һәм органнарында хәрби хезмәт иткән, хезмәт иткән затларны пенсия белән тәэмин итү турында" Рәсәй Федерациясе Кануны нигезендә пенсия алучылар булып торучылардан гайре Рәсәй Федерациясе канунчылыгы нигезендә пенсиянең бер төрен дә яки отставкадагы судьяга түләнә торган айлык гомерлек асрауны алучылар булмасалар.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

2. Пенсия тупланмаларын формалаштыруга дәүләт ярдәме иминиятләштерелгән затлар тарафыннан тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү елыннан килүче елдан соң 10 ел дәвамында гамәлгә ашырыла.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

3. Пенсия тупланмаларын формалаштыруга дәүләт ярдәме алу хокукы алдагы календарь елында тупланма пенсиягә 2000 сумнан да ким булмаган күләмдә өстәмә иминият кертемнәрен түләгән иминиятләштерелгән затларга агымдагы календарь елында бирелә.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 13. Пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашуга кертем күләме**

1. Иминиятләштерелгән затларның пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашуга кертем күләме узган календарь елында иминиятләштерелгән зат тарафыннан тупланма пенсиягә түләнгән өстәмә иминият кертемнәре суммасыннан чыгып билгеләнә, әмма ул елга 12 000 сумнан да артык була алмый.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

2. 2013 елның 28 декабреннән 400-ФЗ номерлы "Иминият пенсияләре турында" Федераль канунның 8 маддәсенең нигезендә иминият пенсиясенә хокуклы булган һәм 2011 елның 30 ноябреннән 360-ФЗ номерлы "Пенсия тупланмалары акчалары исәбеннән түләүләрне финанслау тәртибе турында" Федераль канунның 2 маддәсенең 1 һәм 2 пунктларында каралган иминият пенсиясен, тупланма пенсиясен, вакытыннан алда түләнә торган пенсия түләүен, пенсия тупланмалары акчаларының бер тапкыр түләнә торган түләүен яки Рәсәй Федерациясе канунчылыгы нигезендә башка пенсияләрне, шул исәптән судьяның айлык гомерлек түләүен билгеләү артыннан мөрәҗәгать итмәгән затларның пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашуга кертем күләме

иминиятләштерелгән зат тарафыннан узган календарь елы өчен түләнгән тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәре суммасының 4 тапкырга тапкырланган суммасыннан чыгып түләнә, әмма ул елга 48 000 сумнан да артык була алмый.

(2 өлеш 21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

3. Пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашуга кертем күләме әлеге Федераль канун тарафыннан билгеләнгән пенсия тупланмаларын формалаштыруга дәүләт ярдәме күрсәтү шартларын исәпкә алып Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан һәр иминиятләштерелгән затка карата мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе системасында индивидуаль пенсонафикацияләнгән исәпнең мәгълүматлары нигезендә исәпләнә.

4. Пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашуга кертемлар иминиятләштерелгән затларның пенсия тупланмалары составына кертелә.

**Маддә 14. Пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашуга кертемнәрне күчерү һәм исәпкә алу тәртибе**

1. Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү елыннан соң килүче елның 20 апреленә кадәр пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашуга кирәкле акчаларны федераль бюджеттан күчерү турында гариза җибәрә. Күрсәтелгән гаризаның формасы һәм аны төзү кагыйдәләре Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана. Кирәк булган очракта Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашу өчен федераль бюджеттан пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашу өчен кирәкле акчалар суммасын алдагы гариза җибәргәннән соң өч айдан да соңга калмыйча күчерү турында өстәмә гариза җибәрә.

(1 өлеш 04.06.2018 нән 138-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

2. Пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашуга акчалар Рәсәй Федерациясе бюджет канунчылыгы нигезендә федераль бюджеттан Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды бюджетына Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм шартларда мондый заявканы үтәү агымдагы финанс елына һәм план чорына федераль бюджет турында Федераль канунга үзгәрешләр кертүне таләп иткән очраклардан гайре пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашу өчен кирәкле акчаларны федераль бюджеттан күчерү турында тиешле гариза алган көннән соң килүче 10 эш көненнән дә артмыйча күчерелә. Агымдагы финанс елына һәм план чорына федераль бюджет турында Федераль канунга пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашуга каралган бюджет ассигнованиеләрен арттыру өлешендә үзгәрешләр кертелгән очракта әлеге акчалар агымдагы финанс елына һәм план чорына федераль бюджет турында Федераль канунга әлеге үзгәрешләр кертү турында федераль канун үз көченә кергән көннән соң килүче 15 эш көненнән дә артмыйча күчерелә.

(2 өлеш 04.06.2018 нән 138-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

3. Федераль бюджеттан кергән пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашуга акчалар тиешле финанс елына һәм план чорына Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды Рәсәй Федерациясе бюджет канунчылыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә чагылдырыла. Шул ук вакытта Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды бюджетында әлеге акчаларны идарәче компанияләргә һәм дәүләтнеке булмаган пенсия фондларына тапшыру күздә тотыла.

4. Тиешле финанс елына Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды бюджетын үтәгәндә пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашуга юнәлдерелгән федераль бюджет акчалары белән бәйле операцияләрне исәпкә алу Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан Рәсәй Федерациясе бюджет канунчылыгы нигезендә бюджет исәпкә алуның тиешле счетларында алып барыла.

## Маддә 15.1. Пенсия тупланмалары турында мәгълүматларга төзәтмәләр кертү

(04.06.2018 345-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

1. Эш бирүчеләр, тупланма пенсия өчен өстәмә иминият кертемнәрен түләүче иминиятләштерелгән затлар, шулай ук тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәре буенча физик затларның түләүләрен кабул иткәндә кредит оешмалары тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген тикшерү нәтиҗәләре буенча Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәре, эш бирүче кертемнәре, пенсия тупланмаларын формалаштыруны финанслашуга кертемнәр һәм пенсия тупланмаларын формалаштыруга өстәмә иминият кертемнәре суммасы турында белешмәләргә төзәтмәләр кертә.

2. Әлеге мәгълүматларга төзәтмәләр кертү Рәсәй Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан мөстәкыйль рәвештә яисә иминиятләштерелгән зат, эш бирүче, кредит оешмасы яки башка кызыксынган затның мөрәҗәгате буенча әлеге Федераль канунның 10 маддәсенең 2 өлеше тарафыннан билгеләнгән срок буенча, пенсия белән тәэмин итү системасында норматив-хокукый җайга салу һәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм эшләп чыгару функцияләрен башкаручы федераль башкарма

хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3. Төзәтмәләр нәтиҗәләре иминиятләштерелгән затның шәхси счетының махсус өлешендә чагылдырыла.

**Маддә 16. Үлгән иминиятләштерелгән затларның хокукый варисларына түләүләр**

Тупланма пенсиягә өстәмә иминият кертемнәрен түләү максатларында мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе буенча хокукый мөнәсәбәтләргә кергән иминиятләштерелгән затларның варисларына пенсия тупланмалары акчалары исәбеннән түләүләр тупланмалары акчалары исәбеннән түләүләр өчен "Тупланма пенсия турында" Федераль канун, "Дәүләтнеке булмаган пенсия фондлары турында" Федераль канун һәм "Рәсәй Федерациясендә тупланма пенсияне финанслау өчен акчаларны инвестицияләү" Федераль канун нигезеләрендә каралган тәртиптә түләнә.

(21.07.2014 нән 216-ФЗ номерлы Федераль канун редакциясендә)

**Маддә 17. Әлеге Федераль канунның үз көченә керүе**

1. Әлеге Федераль канун үз көченә 2008 елның 1 октябреннән керә, әлеге Федераль канунның 3 маддәсенең 3 өлешеннән, 5 маддәсенең 3 һәм 4 өлешләреннән, 6, 7 маддәләреннән, 8 маддәсенең 2 – 4 өлешләреннән, 9, 10 маддәләреннән, 11 маддәсенең 4 өлешеннән, 12 маддәсенең 2 – 3 өлешләреннән, 13 – 16 маддәләреннән тыш.

2. Әлеге Федераль канунның 3 маддәсенең 3 өлеше, 5 маддәсенең 3 һәм 4 өлешләре, 6, 7 маддәләре, 8 маддәсенең 2 – 4 өлешләре, 9, 10 маддәләре, 11 маддәсенең 4 өлеше, 12 маддәсенең 2 – 3 өлешләре, 13 – 16 маддәләре үз көченә 2009 елның 1 гыйнварыннан керә.

Рәсәй Федерациясе

Президенты

В.ПУТИН

Мәскәү, Кремль

2008 елның 30 апреле

56-ФЗ номерлы федераль канун